проектлар, җир участоклары һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителү төренә рөхсәт бирү турында карар проекты, капиталь төзелеш объектларына реконструкция, җирдән һәм төзелешләрдән файдалануның расланмаган кагыйдәләре булмаганда алардан файдалануның бер төреннән икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре.

**4 маддә. Җәмәгать тыңлаулары үткәрү инициативасы.**

Җәмәгать тыңлаулары район халкы, район Советы яки район Башлыгы инициативасы белән үткәрелә.

Җирле әһәмияте булган мәсьәләләр буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү өчен район халкы әлеге районда яшәгән һәм сайлау хокукы булган кимендә ун кешедән торган инициатив төркем формалаштыралар. Инициатив төркем формалаштыру турындагы карар җыелышта кабул ителә һәм беркетмә төзелә. Беркетмәдә җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәләләр күрсәтелә, шулай ук инициатив төркем әгъзаларының исем-фамилиясе, атасының исеме, туган елы, эш урыны, вазифасы күрсәтелә.

Җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать иткәнче район Советына инициатив төркем тарафыннан әлеге районда яшәүче һәм сайлау хокукы булган кимендә 100 кешедән имза җыелырга тиеш. Имзалар инициатив төркем төзү турында беркетмә имзаланганнан соң 30 көн дәвамында җыелырга тиеш. Җәмәгать тыңлауларын үткәрүне яклап имзалар җыю имзалар кәгазенә кертелә. Имзалар кәгазенә ФИО, әлеге затның имзасы, адресы, телефоны яки электрон адресы язылa. Имзалар җыю белән бәйле чыгымнарны инициатив төркем күтәрә.

Иницитив төркем җәмәгать тыңлаулары үткәрү тәкъдиме белән район Советына мөрәҗәгать иткәндә түбәндәге документларны тапшыралар:

- җәмәгать тыңлауларына чыгаруга тәкъдим ителүче мәсьәләне күрсәтеп һәм аны нигезләп гариза;
- инициатив төркем әгъзалары турында белешмәләр (ФИО, туган көне, паспорт сериясе һәм номеры, яшәү урыны, имзасы);
- инициатив төркем төзү турында беркетмә;
- җәмәгать тыңлауларына чыгару өчен тәкъдим ителгән документ проекты;
- җәмәгать тыңлауларына кагылышлы информацион һәм аналитик материаллар;
- җәмәгать тыңлаулары үткәрү инициативасын яклап җыелган имзалар. Имзалар кәгазен имзалар җыюны оештырган инициатив төркем әгъзасы имзасы белән тапшырыла, аның ФИО, имза кәгазен раслаган вакыты күрсәтелә.

Район Советы бу документларны 30 көн дәвамында карый.

Җәмәгать тыңлаулары турында мөрәҗәгать район Советының ачык утырышында инициатив төркем әгъзалары катнашында карала. Тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча күпчелек тавыш белән җәмәгать тыңлауларын үткәрүне билгеләү яки нигезләнгән кире кагу турында карар кабул ителә.

